СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ — КАРАР

15.12.2017 с. Нижний Услон 38-153

### Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектының җирле нормативлары турында

Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге башкарма комитетының озак сроклы шәһәр төзелеше сәясәтен булдыру максатларында Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасы һәм 29.4 статьясы нигезендә эшләнгән, Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегендә яшәүчеләрнең уңай тормыш шартларын тәэмин итүгә һәм җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителешнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсендәге гомуми исәпләү күрсәткечләрен һәм мондый объектларның территориаль үтемлелегенең максималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсен билгеләүгә юнәлдерелгән Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектының җирле нормативлары турындагы мәгълүматын тыңлаганнан соң

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1.Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектының җирле нормативларын расларга (1 нче кушымта).

2.Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Түбән Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Советының җир мәсьәләләре, төзекләндерү һәм табигый ресурслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.З.Шайдуллин